Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2026 елның 20 нче январе

№1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 08 июне 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Яңа Арыш » авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 №425-ФЗ Федераль закон нигезендә Совет Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Яңа Арыш авыл җирлеген карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 28 апрельдагы 7 номерлы карарына (18.06.2024 №3, 29.10.2024 №10 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик затның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә вафат булуы турында игълан ителүе (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да, бурыч өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдә бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат булмаганда;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы

Х.С.Зарипов

СОВЕТ НОВОАРЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634001038 ЯҢА АРЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ